РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РАНГАЗАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.48, с. Рангазар,
423359
тел.: (85559)4-36-54,
ОКАТО 92253852000, ОГРН
1061687002420,
ИНН/КПП 1636005415/ 163601001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РАНГАЗАР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет ур.,48 йорт, Рангазар ав,423359
тел.: (85559)4-36-54,
ОКАТО 92253832000, ОГРН
1061687002420,
ИНН/КПП 1636005415 / 163601001

**КАРАР**
**№ 18**
**2018 елның 24 сентябре**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Рангазар авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Рангазар авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыруны инициацияләү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 73 номерлы карары нигезендә, Рангазар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Рангазар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда үзара салым чараларын Рангазар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертүгә сез килешәсезме, моңа I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән дә килешәсезме:

1) Ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:
- Рангазар, Рантамак торак пунктында Сабантуй үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Җиңү көне, Өлкәннәр көне, инвалидлар көненә бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу. Рангазар, Рантамак, Бал-Тамак т.п.;

- Рангазар торак пунктында «Сабантуй» мәйданы территориясендә йорт буяу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү оештыру, шул исәптән:
- махсус техниканы МТЗ-320,4 (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүченең хезмәте өчен түләү);
- Рангазар Рантамак т.п өчен триммерлар сатып алу;
- Рангазар, Рантамак т.п Бөек Ватан сугышы ветераннары йортына мемориаль такта сатып алу.

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шул исәптән:
- Рангазар, Рантамак, Бал-Тамак авылларында юлларны кардан чистарту.

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту, шул исәптән:
- Рангазар, Рантамак, Бал-Тамак авылларында зират территорияләрен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
«Сарман» район газетасында некрологларны бастырып чыгару.

5) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, шул исәптән:
- Рантамак т.п. гидрант өчен янгын сүндерү җиңнәрен, Рангазар т.п. кран өчен янгын сүндерү җиңнәрен сатып алу.

6) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру, шул исәптән:
-Рангазар авылында яшьләр арасында хоккей ярышларын үткәрү өчен бүләкләр сатып алу.

ӘЙЕ ЮК

3. Мәгълүмат стендларында һәм Рангазар авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә әлеге карарны игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Рангазар авыл җирлеге
Советы рәисе Г.Р. Бариев